| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2021 с.Мурали № 5

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.13 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 9 ноябрендәге 370-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 30 сентябрендәге 23 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.7. пунктына түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә: «Татарстан Республикасы законы нигезендә Кайбыч муниципаль районы чикләрендә Мөрәле авыл җирлеге составына керүче торак пункт территориясе өлешендә гражданнарның үзара салымы чараларын торак пункт территориясенең әлеге өлешендә кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча. Әлеге пунктта каралган гражданнарның җыены Мөрәле авыл җирлеге советы тарафыннан кимендә 10 кеше яшәгән торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасы буенча чакырылырга мөмкин.

Кайбыч муниципаль районы чикләрендә Мөрәле авыл җирлеге составына керә торган торак пункт территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү критерийлары гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин муниципаль район чикләрендә урнашкан торак пункт территориясе чикләрен билгеләү критерийлары Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә.».

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан

Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советының 2021 елның 8 февралендәге 1 номерлы карарын юкка чыгарырга.

3.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://muralin-kaybici.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Зиннәтуллин